Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль Районы Советының илле беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль Районы Советы
КАРАРЫ

26 февраль, 2025 ел № 388

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2016 елның 19 апрелендәге 38 номерлы карары белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 13 июлендәге 101 номерлы, 2017 елның 14 сентябрендәге 111 номерлы, 2018 елның 26 апрелендәге 141 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 28 февралендәге 184 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 212 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 249 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 260 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 49 июнендәге 251 номерлы, 2021 елның 23 маендагы 253 номерлы, 2021 елның 22 августындагы 324 елның 23 маендагы 254 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү» 6.3 өлешендә:

- 6.3.10 пунктындагы 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип таныргга;
- 6.3.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3.11. Әлеге Нигезләмәнең 6.3.10 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләре белән бергә аларның төп нөсхәләре дә тапшырыла, алар документларны кабул иткәндә күчермәләре белән кушылалар һәм мөрәҗәгать итүчегә кире кайталар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов